# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 17 гыйнвар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.12, 2.13 статьялар өстәргә:

"2.12 статья. **Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу**

Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен, шулай ук әлеге исәпне алып бару тәртибен гражданнарны исәпкә куюдан йә гражданнарны исәптән төшереп калдырудан законсыз рәвештә баш тартуга китерерлек итеп бозган өчен –

вазыйфаи затларга биш меңнән сигез мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

2.13 статья. **Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм исәпне алып бару тәртибен бозу**

Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә кую тәртибен, шулай ук әлеге исәпне алып бару тәртибен гражданнарны исәпкә куюдан йә гражданнарны исәптән төшереп калдырудан законсыз рәвештә баш тартуга китерерлек итеп бозган өчен –

вазыйфаи затларга биш меңнән сигез мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.";

2) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.13 статья өстәргә:

"3.13 статья. **Умартачылык өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрне бозу**

Умарта кортлары ояларын урнаштырганда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча билгеләнгән таләпләрне бозган өчен –

гражданнарга – ике меңнән дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – биш меңнән тугыз мең сумга кадәр; юридик затларга ун меңнән унбиш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.";

3) 7.1 статьяда "2.11," санын "2.11 – 2.13," саннарына алмаштырырга, "3.12," саныннан соң "3.13," санын өстәргә;

4) 8.1 статьяның икенче өлешендә "2.8," саныннан соң "2.12, 2.13," саннарын өстәргә, "3.11, 3.12" саннарын "3.11 – 3.13" саннарына алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 15 июне
№ 37-ТРЗ